# Пресса как дискурсивный источник

УДК 908

## РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИННЕҢ ДИНИ ҺӘМ МИЛЛИ МӘКТӘПЛӘР ТУРЫНДАГЫ ФИКЕРЛӘРЕ

***Л.Р. Мортазина***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*lyalyamur@mail.ru*

Мәкаләдә күренекле татар галиме, мәгърифәтче-педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Ризаэддин Фәхреддиннең дини һәм милли мәктәпләр турындагы карашлары яктыртыла. 1913 елда Россиянең чит диндәгеләр эшләре буенча департамент башлыгы тарафыннан Диния нәзарәтенә юлланган рәсми хат һәм анда күрсәтелгән сорауларга җавап әзерләү барышында киң җәмәгатьчелекне әлеге сораулар белән таныштыру һәм дөрес караш формалаштыруга ярдәм итү йөзеннән Р.Фәхреддиннең татар вакытлы матбугатында басылган мәкаләләренә анализ ясала.

**Төп төшенчәләр:** Ризаэддин Фәхреддин, милли мәгариф, милли мәктәпләр, дини мәктәпләр, дөньяви мәктәпләр, *«Шура»* журналы, рәсми хат

**Сылтама ясау өчен:** Муртазина Л.Р. Ризаэддин Фәхреддиннең дини һәм милли мәктәпләр турындагы фикерләре // Историческая этнология. 2020. Т. 5, № 2. С. 243–253. https://doi.org/10.22378/he.2020-5-2.243-253

Мәктәп-мәгариф мәсьәләләре XX гасыр башы татар-мөселман даирәсендә күтәрелгән иң әһәмиятле һәм иң мөһим проблемаларның берседер, мөгаен. Яңача укыту кертелү, мәктәп-мәдрәсәләр системасын ислах итү, дөньяви фәннәр укыту татар мәгарифен яңа баскычка күтәрсә, шул ук вакытта хөкүмәт тарафыннан алып барылган сәясәт (1906–1913 еллар аралыгында «инородецлар» мәгарифенә караган кагыйдәләр, проектлар һ.б.), туган телдә укытуны тыю һ.б. – болар барысы да гасырлар дәвамында ныгып-урнашкан, бай тарихлы татар мәгарифенең киләчәген куркыныч астына куя.

1910 елның көзендә Дәүләт думасына гомуми башлангыч белем бирүне кертү турындагы закон проекты кертелә, аның кысаларында милли мәктәпләрдә укыту теле турындагы мәсьәләне тикшерү дә карала. Киң

җәмәгатьчелек әлеге чарада мөселман мәктәпләрен туган тел һәм дин укыту тыелган хөкүмәт мәктәпләренә әвереләдерү куркынычын күрә (Аршаруни, Габидуллин 1931: 41).

> «Рус булмаган халыкларның мәгарифенә карата дәүләт сәясәтенең чагылышы дәүләткүләм гомуми мәҗбүри башлангыч укуга күчү ниятендә һәм земстволар үткәргән сәясәттә дә күренгән. Бу планнар да, земстволарның мәгарифкә мөнәсәбәте дә матбугатның игътибар үзәгендә торган» (Ваһапов 2010: 47).

Закон проекты һәм аңа кагылышлы башка мәсьәләләр татар вакытлы матбугатында зур җанлану белән тикшерелә, хөкүмәтнең мәгариф өлкәсендәге сәясәтен фаш итү, милли мәгарифне әлеге сәясәттән, югалудан саклап калу проблемалары күтәрелә.

Мөселман фракциясе вәкилләре мәсьәләне аңлату, халык фикерен ишетү, бер үк вакытта милли мәктәпләрнең торышын өйрәнү нияте белән Россиянең мөселманнар яшәгән өлкәләренә чыгалар, аңлату эшләре алып баралар. Садри Максуди, мәсәлән, 1910 елның җәендә Идел, Урал, Төркестан, Кавказ буйлап сәяхәткә кузгала, әлеге чара матбугатта һәрдаим яктыртылып барыла (Садри әфәнде Максудовның сәяхәте 1910; Садри әфәнде Бохарада 1910; Садри әфәнде илә мөсахабә 1910).

Билгеле булганча, мөселман мәктәпләре һәр заман хөкүмәтнең күз уңында тотылган: аларның саны, мөгаллимнәре, укытуның куелышы, кулланылган дәреслекләр турында мәгълүматлар даими яңартылып торган. XX гасыр башында, татар-мөселман мәгарифе яңа баскычка күтәрелгән, зур үсеш алган чорда контроль аеруча көчәя: җәдитчелек хәрәкәте һәм җәдит мәктәпләре күбәю белән татарларның башка мөселман халыклары мәгарифенә йогынтысы арту, мәктәп-мәдрәсәләрдә чит илләрдә, шул исәптән Төркиядә, басылган дәреслекләр, әсбаплар кулланылу, чит илләрдә белем алган мөгаллимнәр белем бирү һ.б. «рус дәүләтчелеге мәнфәгатьләренә куркыныч тудырган» мәсьәләләр өзлексез тикшерелеп тора. Ләкин аерым урыннарда, мәсәлән, Төркестанда, халык мәктәпләре инспекторларының җирле халыкларның телләрен белмәве яки начар белүе мөселман мәктәп-мәдрәсәләренең эшчәнлеген тулы бәяләргә мөмкинлек бирмәгән. Мәсьәләне хәл итүнең бер юлы буларак әлеге мәгълүматларны мөселманнарның үзләреннән алу юлы карала. 1913 елның 12 сентябрендә Россия Тышкы эшләр министрлыгының чит диннәр эшләре буенча департаменты директоры Е.В. Менкиннан Оренбург мөфтие М. Солтанов исеменә мөселман мәктәпләре хакында закон ләйхасы төзү өчен кирәкле булган мәгълүматлар соралып җибәрелгән 8441 нче номер астындагы рәсми хат шундый максатларны күздә тота. Хатта күрсәтелгәнчә, әлеге чарадан хөкүмәтнең максаты – мөселман мәктәпләренең асылы, максатлары, фәннәрне укыту юллары, укыту программасы, педагогик тәэмин ителеше, дин укытуның эчтәлеген һәм әлеге мәсьәләләрнең ислам дине кагыйдәләре ягыннан чыгып караганда ни рәвешле дәлилләнүен

ачыклаудан гыйбарәт була. Бу хатның эчтәлеге һәм гомумән аның татар-мөселманнар арасында ни рәвешле кабул ителүе күренекле татар галиме һәм җәмәгать эшлеклесе Риза Фәхреддиннең *«Шура»* журналының 1913 елгы 24, 1914 елгы 2 нче саннарында басылып чыккан *«Дини вә милли мәктәпләребез хакында»*, *«Дини вә милли мәктәпләребез»* дигән мәкаләләрендә җентекле тасвирлана[1]. Әлеге мәкаләләр күренекле мәгърифәтченең дини һәм милли мәгариф турындагы фикерләре тулы гәүдәләнеш алган әһәмиятле хезмәтләрдән саналырга хаклы.

Мәкаләләр әлеге вакыйганы киң җәмәгатьчелеккә аңлату, аның төп эчтәлеге белән таныштыру максатыннан язылган. Бер яктан, хөкүмәтнең милли мәгариф эшләрен даими күзәтчелектә тотуы, аңа тыкшынуы милләт мәнфәгатьләре ягыннан чыгып караганда бик үк күңелле күңелгә ятышлы күренеш булмаса да, Р. Фәхреддинов аның уңай якларын да күрә:

> «Зур бу милләтнең дини мәктәпләре хакында закон ләйхасы төзү вакытында мәзкүр милләтнең дини кагыйдәләрен вә гомумән шуңа мөнәсәбәтле нәрсәләрне шул милләт галимнәренең үзләреннән тугры ишетеп белү вә ләйханы да шуңа бинаэн кылып төзү бик яхшы эш» (Фәхреддин 1913а: 737).

Р. Фәхреддин татар җәмәгатьчелеген әлеге хатның эчтәлеге белән таныштыру максатыннан аның кулларда йөри торган бер нөсхәсен ирекле рәвештә тәрҗемә итә:

> «Хәзерге вакытта Министерство Мәмләкәтнең һәр тарафтагы мөселман дини мәктәп вә мәдрәсәләренең бүгенге хәле хакында үз кулында булган материалларны рәткә салырга керešте. Ошбу мөнәсәбәт илә мөтәхассыйс (белгеч – Л.М.) булган затларның үтенечләре буенча мөселманнарның дини тәгълимгә турыдан-туры мөнәсәбәте булган шәригать карарларын белергә ихтыяҗ тапты. Шул сәбәпле үтенәмез: шәригатьтә мөхәммәдиләрнең дин тәгълим итә торган школларының назначениесе (мәүзугы), алардан көтелгән максатлар, аларга тәгълим тәртибе, укытылачак нәрсәләр вә программ, мөгаллимнәр һәйяте вә бала һәм егетләргә дин үгрәтергә алынган кешеләрнең нинди сәляхиятләре (сәләтләре, осталыклары. – Л.М.) хаиз булулары (җыйнавы, эченә алуы. – Л.М.) хакында гомумән бәяннар бармы, булса нindиләр?» (Фәхреддин 1913а: 738).

Р. Фәхреддин әлеге мәсьәлә буенча үзенең фикерләрен җиткерү кирәк дип таба, шул сәбәпле киң җәмәгатьчелекне әлеге сораулар белән таныштыру өстенә, күпчелектә аларга карата дөрес караш булдыруны да максат итә. Шул сәбәпле ул гомумән дини һәм милли мәктәпләр төшенчәләрен аңлатуга аеруча киң туктала. Бүгенге көндә, Фәхреддин

[1] Әлеге мәкалә шулай ук «Вакыт» газетасының 1913 елгы 6 декабрь санында да дөнья күрә.

фикеренчә, уку урыннары максаты һәм көтелгән нәтиҗәгә бәйле рәвештә «дини» һәм «дөньяви» исемендә ике сыйныфка аерыла:

> «Әгәр дә максуд дин илә ашналык хасыйл итү (таныштыру. – Л.М.) вә дини эшләрдә башкаларга караганда беркадәр ихтисас (белгеч. – Л.М.) кәсеп итү булса, ул мәктәп "дини" исемләнә. Әгәр дә аннан максуд дөнья көтәргә сәбәп була торган һөнәр вә сәнәгать үгрәнү булса, анысы "дөньяви" буладыр. Бу эштән "дини" мәктәптә дөньяви эшләр вә "дөньяви" мәктәпләрдә дини гыйлемнәр укымак дип аңларга тиешле түгел. "Дини" мәктәпләрдә дөньяви һөнәрләр вә дөньяви мәктәпләрдә дини гыйлемнәр укытылырга мөмкин, ихтимал бәгъзе вакытларда бу эш лязем булып та килер. Бәлки дини вә дөньяви исемнәре, югарыда әйтдекемезчә, максуд вә гаять ихтияри илә генә биреләдер» (Фәхреддин 1913а: 738).

Диния нәзарәте карамагында булулары дини мәктәпләрне билгеләүче төп билге. Шул ук вакытта, дини мәктәпләр дини фәннәрне укыту белән генә һич чикләнмәскә тиешләр. Р. Фәхреддин үзенең фикерен раслау өчен түбәндәге фактны китерә:

> «Мисырда дәгъвәт вә иршад исемендә дини бер мәдрәсә ачтылар яки ачалар. Моның программында бу көндә ихтыяҗ күрелгән фәннәрнең һәрбере, хәтта Аурупа телләреннән бер-икесе мәҗбүри итеп күрсәтеләдер. Мисыр мөфтие Мөхәммәд Габдүһү хәзрәтләренең "Бу заманда ислам диненең галиме саналыр өчен Аурупа телләренең һич булмаганда берсен белү шарт, Аурупа телләреннән берсен генә дә белгән адәмгә дин галиме исеме бирелү ялгыш эш" дигән сүзе мәшһүрдер. Инде дин галимнәре чыгарыр өчен тәэсис кылына (оештырыла. – Л.М.) торган мәктәпләрдә берәр төрле чит тел укытылмаса, ул мәктәпләр дин галимнәрен ничек җитештерә алыр?» (Фәхреддин 1913а: 738).

Шул ук вакытта ул:

> «Дөрес, Мөхәммәд Габдүһүнең ул сүзе Коръән вә хәдис маснүне (гадәт итеп алынган. – Л.М.) түгел. Фикһедә исаэ ителеп (васыять ителеп. – Л.М.) тотыла торган бер кагыйдә дә түгел; шуның өчен аңа колак салмаганлыктан бер зарар да булмый. Шулай булса да, мәзкүр сүз, дөрес тәҗрибәләрә бинаэн ителгән тугры бер "хакыйкать"тер. Аны инкарь кылучы, Аллаһ каршында гөнаһлы булмаса да, аңлап сөйләүчеләрдән хисап кылынмас», – дип белдерә (Фәхреддин 1913а: 738), чит телләр өйрәнүнең мөһимлеген ассызыклап.

Фәннәр өйрәнүнең әһәмиятен нигезләп, Р. Фәхреддин:

> «Ислам дине, фән уку хакында турыдан-туры фәрман биргән булмаса да, һәлакәттән, заляләттән (ялгыш юлга керү, хаталану. –

Л.М.), хәсрәт вә фәләкатьтән саклану илә һәм тугры һәм ачык фәрман биргәнлеге мәгълүм», – дип яза (Фәхреддин 1913а: 738).

Рәсми хаттагы дини мәктәпләргә караган вазгыятьне шәригать күзлегеннән чыгып аңлатма бирү үтенеченә килгәндә, Р. Фәхреддин фикеренчә,

> «Заман вә урын үзгәрүе сәбәбеннән үзгәрми һәм башкармый торган нәрсәләр хакында шәригать ачык тәгълимат бирсә дә, заман һәм вакыт үзгәрүе сәбәбеннән үзгәрергә вә башкарырга мәҗбүрият була торган яки "табигыйлык" дәрәҗәсенә җиткән нәрсәләрнең бик күбесе хакында шәригать шул заман галимнәренең мәслихәтләренә тапшырадыр», ди, ягъни кешеләрнең «үзләрен ахирәттә вә дөньяда һәлак булудан саклаячак нәрсәләрне белү, үгрәнү шәригать тарафыннан ачык сурәттә фәрманнар илә тәэкид кылына (раслана. – Л.М.), әмма белү вә үгрәнү кәфиятләрене тәгаен әйтү исә дә гасырның үз балаларына амәнәт ителенәдер» (Фәхреддин 1913а: 738).

Шул рәвешле галим дини мәктәпләрнең максат һәм бурычларын, эчтәлеген билгеләүдә шәригать кануннары белән беррәттән заман таләпләренең дә роле зур булуын раслый.

Укыту ысуллары, билгеле булганча, һәр чор өчен аермалы, үзенчәлекле була, шул сәбәпле аларны бернинди үзгәрешсез озак гасырлар дәвамында куллану мөмкин түгел.

> «Ибн Мәскәүвия (Ибн Мискавейх. – Л.М.) вә имам Газәли төзегән программнарның бәгъзе урыннары безнең гасыр өчен уңай булмаса, безнең гасырыбызда төзелгән файдалар вә программнарның да беразы яки бөтенләе киләчәкләр өчен эшкә ярамавы мөмкин», – ди автор (Фәхреддин 1913а: 738).

Шуңа күрә, аның карашынча, тәгълим тәртибе вә тәгълим программалар хакында шәригать тарафыннан бирелгән тугры фәрманнар күрсәтү бик авыр, чөнки даими үзгәреп торуы тиеш булган эшләр хакында ислам шәригатенең турыдан-туры фәрман бирүе мөмкин түгел. Шуңа күрә дә гыйлем өйрәнү мөселманнар өчен фарыз булса да, аның тәхсыйл кәфияте тәгаен кылу һәр гасыр мөселманнарының үзләренә тапшырыла.

Хат барлыгы алты сораудан гыйбарәт, аларга җавапларны биргәндә Коръән һәм хәдисләргә нигезләнеп дәлилләү сорала. Р. Фәхреддин бу эшнең хөкүмәт адәмнәре өчен дә, мөселманнар өчен дә уңайсыз, мәшәкатьле эш булганлыгын әйтә:

> «Әгәр дә, – ди ул, сынау өчен генә булса да, мәзкүр сөальләр илә Инҗил вә Тәүрат галимнәренең мөрәҗәгать итсәләр вә: "Шушы хакта шәргый бәяннар бармы, булса алар нәрсәләр?" дип сорасалар, зан итәмез ки: Инҗил вә Тәурат галимнәре дә җавап бирү турысында уңайсызлыклар күрерләр, вә моның бер мәшәкатьле хезмәт икәнлеген

сөйләрләр. Хәлбуки алар хакында тәрҗемә мәшәкатьләре бөтенләй юктыр» (Фәхреддин 1913а: 739).

Р. Фәхреддин фикеренчә, хөкүмәт өчен закон проекты төзелгән вакытта аның дини дәлилләргә нигезләнүе түгел, бәлки дини кануннарга каршы һәм милләтләр өчен зарарлы булмавын гына күз уңында тоту муафикъ. Бу турыда хөкүмәтнең рәсми вәкиле булган мөфтинең «шундый нәрсәләр ислам шәригатенә хилаф түгел», дип биргән фәтвасы, христиан руханилары тарафыннан бирелгән җаваплар кабиленнән хөкүмәт вәкилләре һәм Дума мәҗлесе өчен төп дәлил булырга тиешле.

Мөселманнарның дини мәдрәсәләрдә фәннәр уку хокукы булырга, дини дәресләр ана телендә һәм гарәп телендә укылырга тиешле. Әгәр дә мөселманнар өчен шул рәвешле тәртипләр оештырыла калса, Р. Фәхреддин карашынча, моннан мөселманнар гына түгел, хөкүмәт даирәләрендәгеләр үзләре дә файда күрәчәкләр. Шулай ук, мәгърифәтче фикеренчә, проект төзелеп беткәннән соң, Думага тәкъдим ителгәнче тагын бер тапкыр мөселманнарның дини идарәләренә һәм зыялыларга күрсәтелеп үтелсә, эш барышында ачыкланган аерым кимчелекләр һәм җитешсезлекләр төзәтелсә, бу ике як өчен дә яхшы булачак.

Риза Фәхреддин алда искә алынган рәсми хаттагы сораулар белән журнал укучыларын таныштыра һәм аларга үзе әзерләгән җавапларны да урнаштыра. Бу сораулар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. «Мөселманнарның дин тәгълимат итә торган мәктәпләрнең назначениесе нинди нәрсә?

2. Шул мәктәпләрдән көтелгән максудлар нинди нәрсә?

3. Аларда тәглим тәртипләре ничек?

4. Укытылачак нәрсәләр вә програмнар нинди нәрсә вә нинди рәвештә?

5. Мөгаллимнәр һәйяте һәм дин мөгаллимнәре нинди сәляхиятләре хаиз булулары тиеш?

6. Ошбу хосусларда ислам шәригатендә бәяннар бармы? Булса, ниндиләр?» (Фәхреддин 1913а: 739).

Әлеге сорауларга бирелгән җавапларда галимнең дини мәгариф, дини мәктәп-мәдрәсәләр һәм аларның эчтәлегенә караган фикерләре тулаем чагылыш таба. Беренче сорауга ул болай дип җавап бирә:

> «Дин тәгълим итәлә торган мәктәпләрнең асыл вазыйфалары Аллаһы Тәгаләгә булган бурычларын да вә үз араларында бер-берсенә каршы булган хакларын да үти алырлык динле, игътикадлы вә тәрбияле, гүзәл әхлаклы вә фали инсаннар җитештермәкдер» (Фәхреддин 1913а: 739).

Алардан көтелгән максат та, автор фикеренчә, «ислам дине илә ашна (таныш – Л.М.) булмактадыр. Соңгысы исә өч дәрәҗәгә аерылырга мөмкин:

«Мөселман булу өчен шарт ителгән кадәр игътикад (чын күңелдән ышану – Л.М.) вә гамәл рәвешләрен белү; моның өстенә беркадәр дәлилләрне аңлый алу; мәзкүр нәрсәләрнең хикмәтләрен вә дәлил чыгару юллары бар, бу дәрәҗә кыяс кыла (чагыштыру – Л.М.) торган вә иҗтиһад (тырышлык – Л.М.) илә белүгә кадәр барадыр» (Фәхреддин 1913а: 739).

Р. Фәхреддин, педагогиканың төп принципларына таянып, дини мәктәпләрдә тәгълим-тәрбиянең мөмкин кадәр җиңел юлда алып барылу һәм файдалы булу таләбен алга сөрә, иң кирәклердән кирәкләргә күчә барудан гыйбарәт булырга тиешлеген ассызыклый. Укытылачак предметлар һәм программалар мәсьәләсенә килгәндә, алар белем бирүгә карата куелган максатлар белән турыдан-туры бәйле:

«Беренче дәрәҗә өчен игътикад вә гамәли рәвешләрен ялгыз ана теле илә генә дә аңларга мөмкин. Икенче дәрәҗә өчен бераз гарәп лөгате вә гомум гарәбия белергә тиешле, өченче дәрәҗә өчен Коръән кәримне аңларга вә дәлилләрне дөрес йөртергә ярдәм бирә торган фәннәрне вә моның өстенә дә голүм гарәбия вә гарәп лисанын камил сурәттә белергә тиешле». Шушы өч максат һәм алардан көтелгән нәтиҗәләрне күз алдында тотып, ул «мөселманнарның мәзкүр өч дәрәҗә өчен үзләренә муафикъ сурәттә дини мәктәпләр булырга хаҗәт бар», дип нәтиҗә ясый (Фәхреддин 1913а: 739).

Мөгаллимнәр һәйәте һәм дин мөгаллимнәренә хас булырга тиешле сәләт, мөмкинлекләргә килгәндә, Риза Фәхреддин мөселман дини мәктәпләрен башка халыклар, мәсәлән, христиан диненә караган мәктәпләрдән аерып карамый: «христиан дине нисбәт итә нинди сәляхиятләрне хаиз булырга лязем күрелсә, мөселманнарның динен мәдрәсәләрдәге мөгаллимнәр һәйәте илә мөгаллимнәр дә шундый сәляхиятләрне хаиз булырга тиешләр», ди (Фәхреддин 1913а: 739). Алдагы җавапларга нигез, дәлил итеп, автор карашынча, «Төркия, Мисыр вә башка мәмләкәтләрдәге ислам галимнәрен күрсәтергә мөмкин» (Фәхреддин 1913а: 738).

Билгеле булганча, әлеге рәсми анкетага җаваплар һәм закон проектын әзерләгәндә ислам галимнәре, имамнарның фикерләре төп урынны алырга тиеш. Р. Фәхреддиннең алда искә алынган мәкаләсе мөселман җәмгатьчелеген ялгыш җаваплардан саклау максатыннан чыгып язылган. *«Шура»*ның 1914 елгы санында басылып чыккан *«Дини вә милли мәктәпләребез»* дип исемләнгән икенче бер мәкаләсендә ул ислам голямасының әлеге сорауларга җавап әзерләү процессын тасвирлый.

Мәкаләдән билгеле булганча, сораулар аерым бланкларга языльп, Оренбург мөфтие тарафыннан үз кул астында булган муллаларның кайберләренә таратыла, аларның бу хакта фикерләре сорала. Моннан тыш, 10 декабрьдә мөфти беркадәр муллаларны үз каршына җыеп, әлеге мәсьәлә буенча ачыклык кертү максатыннан махсус бер киңәш мәҗлесе

җыярга карар кыла. Тик, күп тә үтми, әлеге чараның мөфтинең үз белдеге белән генә оештырылуы, хөкүмәттән рөхсәт алынмавы сәбәпле, мәҗлес җыю турындагы карар кире кагыла. Ләкин, шулай булуга карамастан, 10 декабрьдә 30 дан артык ахун, мөдәррис һәм имам җыела: күбесе, инде юлга чыгу сәбәпле, килмәгез дигән кәгазьне алмаган; кайберләре, белеп тә, әлеге чараның мөселманнар өчен никадәр мөһим булуын аңлаган хәлдә, Уфага килергә карар кыла. Мәҗлес уздыруга мөфтинең рөхсәт бирмәячәген аңлаган хәлдә, муллалар, Бәләбәй мәчете ахуны Җамалетдин Хурамшин, Мәскәү мәчете имамы Габдулла Шәмсетдинов, бөтен җаваплылыкны үз өсләренә алып, Уфа губернаторы аркылы 10–14 декабрьдә мәҗлесне ясар өчен министрдан рөхсәт сорыйлар. Хатка кушымта итеп мәҗлеснең программасын һәм катнашачак кешеләрнең исемлеген язып тапшыралар. Министр рөхсәт бирә, бу хактагы телеграмма кәгазе 13 декабрьдә килеп ирешә. 14 декабрьдә имамнар һәм ахуннар Оренбург диния нәзарәте залына җыелалар. Җыелышка исемлектә булмаган чит кешеләр, хәтта газета мөхәррирләре дә кертелми. Р. Фәхреддин билгеләвенчә, бу кысынкылык министр һәм губернатор тарафыннан билгеләнми, мәҗлесне оештыручыларның үзләренең шулай хәл итүе белән генә эшләнә.

Мәҗлестә катнашучылар арасында Петербургның икенче мәхәллә имамы Мөхәммәтзариф Юнысов, Мәскәүнең 1 мәчет имамы Габидулла Шәмсетдинов, Сембердән Мөхәммәтшакир Гаффаров, Тамбов губернасыннан Хәсән Таһиров, Бәйрәкә имамы Мәсгуд Гобәйдуллин, Сергачтан Җәлалетдин Сакалов, Төмән өязеннән Йосыф Сәгыев, Златоусттан Әхмәтсафа Баһаветдинов, Шадриннан Габделвәкил Мөслимов, Уфадан Җиһангир Абзгилдин, Пәрвазетдин Камалетдинов һ.б. – барлыгы 22 кеше була (Фәхреддин 1914: 38).

Җыелышта директор юллаган сораулар укыла, һәм имамнардан аларга җаваплар язып алына (автор аларны мәкаләсендә урнаштыра). Шул ук көнне кичен әлеге җаваплар рәсми хат бланкысына урнаштырыла һәм раслана, әлеге чарада катнашкан имамнар тарафыннан имза куела. Рус теленә тәрҗемә итеп, чит диндәгеләр эшләре департаменты директорына җибәрергә карар кылына.

Җаваплар Р. Фәхреддин фикерләре белән нигездә тәңгәл килә. Ул бу хакта үзе дә әйтеп уза. Күпчелек очракта җаваплар киңрәк, җентекләбрәк бирелгән. Мәсәлән, укытылачак предметлар турында сүз барганда, җыелышта кабул ителгән документта мәктәптә һәм мәдрәсәләрдә укытылачак предметларның төгәл саннары күрсәтелә, алар санап кителә: мәктәпләрдә 16 төрдәге фәннәр (алар арасында ана телендә уку-язу кагыйдәләре белән имля вә инша, Коръән, гыйльме халь, гыйльме әхлак, тарих мөкатдә, тарихы ислам, тарих милли, Русия тарихы, җәгърафия, хисап, хифзы сыйххәт һ.б. бар), мәдрәсәләрдә, мәктәптә укытыла торган предметлардан тыш, тәфсир, кыйраәт, гыйльме кялям, фикһе, мантыйкъ, гарәп теле һәм әдәбияты, тарихлар, хөкүмәт лисаны (ягъни рус теле), ысул тәгълим, фарсы теле, икътисад, төрки әдәбияты, һәндәсә, моназара,

фәлсәфәи диния, голүм кимия кебек фәннәр (барлыгы 36 предмет) санап узыла (Фәхреддин 1914: 40–41). Р. Фәхреддин әлеге сорау буенча алдан ук борчылуын, һәм, шатлыкка, аның уңай хәл ителүен белдерә: «Уфада булган җәмгыятьнең дини мәдрәсәләрдән фәннәрне сөрмәк тарафында булуларындан хәвефемез зур иде. Чөнки фән сөрелсә, диннең дә сөрелүе лязем булачыгында шөбһәмез юк иде» (Фәхреддин 1914: 42). Моның өстенә, имамнар тарафыннан бирелгән һәрбер җавап аять һәм күпсанлы хәдисләр белән дәлилләнүе дә хөкүмәт тарафыннан куелган таләпләргә җавап бирә. Шул рәвешле Риза Фәхреддин әлеге мәҗлестән һәм анда каралган мәсьәләгә карата әйтелгән фикерләрдән риза булуын белдерә, чарада катнашучылар арасында бик мәшһүр, атаклы затларның булуын, әлеге җавапларның мөселманнар һәм аларның мәгарифе өчен ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын раслый.

Ризаэддин Фәхреддиннең татар матбугатында басылып чыккан әлеге мәкаләләрендә галимнең милли мәктәп-мәдрәсәләр, аларның эчтәлеге, максатлары, үзенчәлекләре, яхшырту чаралары турындагы һ.б. фикерләре чагылыш таба. Бу хезмәтләр шул заман татар җәмәгатьчелегендә татар мәктәпләренә карата дөрес караш формалаштыруда зур әһәмияткә ия.

## ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ МАТЕРИАЛЛАР

Садри әфәнде Максудовның сәяхәте 1910 – Садри әфәнде Максудовның сәяхәте // Вакыт. 7 сентябрь 1910.

Садри әфәнде Бохарада 1910 – Садри әфәнде Бохарада // Вакыт. 22 сентябрь 1910.

Садри әфәнде илә мөсахабә 1910 – Садри әфәнде илә мөсахабә // Вакыт. 5 октябрь 1910.

Фәхреддин 1913а – Фәхреддин Р. Дини вә милли мәктәпләребез хакында // Шура. 1913. № 24. Б. 737–740.

Фәхреддин 1913б – Фәхреддин Р. Дини һәм милли мәктәпләребез // Вакыт. 6 декабрь 1913.

Фәхреддин 1914 – Фәхреддин Р. Дини вә милли мәктәпләребез // Шура. 1914. № 2. Б. 37–42.

## ФӘННИ ӘДӘБИЯТ

Аршаруни А., Габидуллин Х. Очерки панисламизма и пантюркизма в России. М., 1931.

Ваһапов Н.Ә. Татар вакытлы матбугатында мәгариф һәм тәрбия мәсьәләләренең чагылышы (1907–1916 еллар). Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2010.

**Автор турында белешмә:** Мортазина Ләлә Рәис кызы – педагогика фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре (420111, Батурин урамы, 7А, Казан, Россия Федерациясе); lyalyamur@mail.ru

*Редакциягә керде 29.05.2020* *Басылуга кабул ителде 02.11.2020*
*Басылды 25.11.2020*

## THE VIEWS OF RIZA FAKHREDDIN ON RELIGIOUS AND NATIONAL SCHOOLS

***L.R. Murtazina***

*Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*lyalyamur@mail.ru*

The article analyzes the famous Tatar scholar, teacher, enlightener, and public figure Riza Fakhreddin's opinion on Muslim national and religious schools. Fakhreddin's publications published in the Tatar periodical in 1913–1914 served as a source for writing the work. In 1913, Mufti M.Sultanov received an official letter from the Department for Foreign Confessions of the Ministry of Internal Affairs of Russia. The letter requested Muslims' opinions about the situation of religious schools from the Islamic perspective. In his works, Fakhreddin gives the questionnaire answers and covers the Muslim community's opinion about this document.

**Keywords:** Riza Fakhreddin, national education, national schools, religious schools, secular schools, Shura magazine, official letter

**For citation:** Murtazina L.R. Rizaeddin Fäkhreddinneñ dini häm milli mäktäplär turyndagy fikerläre [The Views of Rizaeddin Fakhreddin on Religious and National Schools]. *Istoricheskaya etnologiya*, 2020, vol. 5, no. 2, pp. 243–253. https://doi.org/10.22378/he.2020-5-2.243-253

## REFERENCES

Arsharuni A., Gabidullin H. *Ocherki panislamizma i pantjurkizma v Rossii* [Essays on Pan-Islamism and Pan-Turkism in Russia]. Moscow: Bezbozhnik, 1931. (In Russian)

Vagapov N.E. *Tatar vakıtlı matbugatında mägarif häm tärbiyä mäsälälärenеñ çagılışı (1907–1916 yıllar)* [Problems of Education and Upbringing in Tatar Periodicals (1907–1916)]. Kazan: RT Academy of Sciences Institute of History Publ., 2010. (In Tatar)

*Мортазина Л.Р.* Ризаэддин Фәхреддиннең дини һәм милли мәктәпләр турындагы фикерләре

**About the author:** Lyalya R. Murtazina is a Cand. Sc. (Pedagogy), Leading Research Fellow of the Center of History and Theory of National Education, Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7A Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); lyalyamur@mail.ru

*Received May 29, 2020* *Accepted for publication November 02, 2020*
*Published November 25, 2020*

## ВЗГЛЯДЫ РИЗЫ ФАХРЕДДИНА НА РЕЛИГИОЗНЫЕ И НАЦИОНАЛЬНЫЕ ШКОЛЫ

***Л.Р. Муртазина***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*lyalyamur@mail.ru*

В статье анализируются взгляды известного татарского ученого, педагога, просветителя и общественного деятеля Ризаэддина Фахреддина на проблему национальных и религиозных школ мусульман. Источником послужили публикации Фахреддина в татарской периодической печати за 1913–1914 годы. В 1913 году муфтием ОМДС М. Султановым было получено официальное письмо от Департамента духовных дел иностранных исповеданий Министерства внутренних дел России, где спрашивалось мнение мусульман о состоянии религиозных школ с объяснением их на основе постулатов исламского вероучения. В своих работах Фахреддин дает ответы на вопросы анкеты, а также освещает мнение мусульманской общественности об этом документе.

**Ключевые слова:** Ризаэддин Фахреддин, национальное образование, национальные школы, религиозные школы, светские школы, журнал «Шура», официальное письмо

**Для цитирования:** Муртазина Л.Р. Ризаэддин Фәхреддиннең дини һәм милли мәктәпләр турындагы фикерләре // Историческая этнология. 2020. Т. 5, № 2. С. 243–253. https://doi.org/10.22378/he.2020-5-2.243-253

**Сведения об авторе:** Муртазина Ляля Раисовна – кандидат педагогических наук, ведущий научный сотрудник Центра истории и теории национального образования Института истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан (420111, ул. Батурина, 7А, Казань, Российская Федерация); lyalyamur@mail.ru

*Поступила 29.05.2020* *Принята к публикации 02.11.2020*
*Опубликована 25.11.2020*